

2018нче ел, август
Урам көне үтте бүген гөрлә
Җыелышкан дуслар,
туганнар


Бер күрешик,очрашыйк диеп,
Ерак-еряклардан кайтканнар.

Яланнарда атлар уртлап йөрми,
Су эчертеп йөрми кызлар да,



# Минем бэбкэм кубрэк , дигэн кебек
# Горур кангылдамый казлар да



Төпчек кызын сагынып көткән кебек,
Колач җәеп каршы алды ялан.



# Яланаяк, тәкыя үреп йөргән,
# Балачагым шул яланда калган




Кая китте синең мал-туарың,
Кая китте чабыш атларың?


Кая китте дөнья көтеп йөргән
Нык адымлы зирәк
картларың?


Ялан матур, тик күңеле-
моңсу,
Салмак  тирбәләләр таллар
да
2018-8-18 14:2


Ялан белән бергә картайганын
Аңлый микән әллә алар да?

**Урам көне үтте бүген гөрләп,**
**Җыелышкан дуслар, туганнар.**
**Йөрәгенә –шифа, җанга дәва эзләп,**
**Яшьлек яланына кайтканнар.**

